Мәкаләдә Нәкый Исәнбәтнең тәрҗемә эшчәнлеге тикшерелә. Аның рус классик әдәбиятыннан тәрҗемәләре, аерым алганда А. С. Пушкинның «Бакчасарай фонтаны» һәм «Полтава» әсәрләренең аерым фрагментлары анализ материалы булып тора. Рус классикасына мөрәҗәгать итүнең мәдәни-идеологик контексты, элгәргеләр белән чагыштырганда техник яңалыклары, шулай ук сүз остасының тәрҗемә принциплары кебек мәсьәләләргә игътибар юнәлтелде. Төп нөсхә мәгънәсенең төгәллеге, яңа, тәрҗемә текстының туган (татар) теленең нормаларына, аның эстетик алымнарына туры килүе, рус сүз сәнгатенең тасвирланган дөньясына тирәнрәк үтеп керү тәрҗемәче Нәкый Исәнбәт стиленең мөһим элементларыннан санала. Киләчәктә теманы өйрәнүне, һичшиксез, дәвам итү сорала.

**Төп төшенчәләр:** Нәкый Исәнбәт, рус әдәбияты, татар теле, әдәби тәрҗемә, чагыштыру һәм тиңләштерү, мәгънәви үзгәрешләр.

Нәкый Исәнбәтнең киңкырлы иҗат мирасында әдәби тәрҗемәләр үзенчәлекле урын алып тора. Язучы эшчәнлегенең бу ягы хакында яхшы билгеле булса да, бүгенге көнгә кадәр ул системалылыктан ерак булган очраклы төстә генә гыйльми-филологик күзалланган: Н. Исәнбәтнең теге яки бу чор тәрҗемәсен гади фактографик аспектта гына билгеләп үтү аз, ә туган тел чаралары белән чит мәдәният образын тудырганда, ул таянган сәнгати стратегияне, ул эшләгән социаль-тарихи контекстны, тәрҗемәнең сайлану принципларын һәм, ниһаять, автор яңалыгының ничек чагылышын ачыклау мөһим. Күләмле булмаган бер мәкалә чикләрендә генә бу проблемаларны иңләп алу мөмкин түгеллеге аңлашыла.

Татар тәрҗемәчелеге тарихында Н. Исәнбәт – үзенчәлекле фигура һәм маяк, бер этап. Сүз уңаеннан, аны киләчәктә язу кирәклеген ассызыкларга кирәк. Дөрес, татар әдәбият белемендә тәрҗемә, аның тарихы, принциплары һәм төрләре мәсьәләләренә күпсанлы хезмәтләр һәм мәкаләләр багышланган ([Аврутина, Хабутдинова], [Галиуллин, Хабутдинова, 2014], [Нагуманова, 2017], [Сайфулина, Валеева, 2017] һ.б. лар). Н. Исәнбәттә тәрҗемәчелек темасын бөтенлекле, тулы канлы өйрәнү өчен, авторның – тәрҗемәче ниятенең үсешен детальләрдә күзәтү (аңлы рәвештә булмаса да, ул һәрвакыт яши. – *Р.Б.*), аның оригиналны конкрет лексик-семантик һәм коммуникатив-синтаксик чишелештә эшкәртү техникасын ачыклау, чит тел язучыларын язучы тәрҗемә итә башлаган чорны да истә тотып, Идел-Урал буе татарларында тәрҗемә эшчәнлеге торышына гомуми күзәтү ясау мөмкинлеге биргән кульязма фондыннан башлап төрле чыганакларына кадәр өйрәнергә кирәк булыр иде. Рус сурәтле-әдәби сүзнең мәгънәсен бирү процессында, Н. Исәнбәт файдаланган төп юлларны өйрәнү безнең тыйнак максатыбыз булып тора.

Гомумән алганда, Н. Исәнбәт дөнья – рус сүз сәнгатенең генә түгел, ә көнбатыш, көнчыгыш – әдәбиятының гүзәл әсәрләрен тәрҗемә итү белән шөгыльләнә. Татар халкының мәдәни күтәрелеш дәвере – XX гасыр башы традицияләре дәвамчысы булган язучы аңлы һәм максатлы рәвештә төп нөсхәгә, оригиналга мөрәҗәгать итә. Мәсәлән, кайбер биографик күрсәткечләрдә 1940 елларда Шекспирның «Гамлет»ын тәрҗемә итү өчен, Н. Исәнбәтнең инглиз телен махсус өйрәнү факты әйтелә [Әдипләребез: биобиблиографик белешмәлек, б. 613]; ул рус тәрҗемә копиясе аша түгел, ә дөньякүләм танылган драматург һәм аның тарафыннан язылган текст белән тыгыз һәм ышанычлы диалог өчен шартлар барлыкка китерү максатыннан эшләнә[1].

[1] Н. Исәнбәт тарафыннан, үз максатын ачык аңлаган һәм, күпсанлы «тактик» каршылыкларга карамыйча, намуслы үтәлгән һәм аны, ялган пафоссыз бөек, чын

Ул рус әдәбияты фондыннан XIX гасырның икенче яртысы классикларын нәтиҗәле тәрҗемә итә. Бу тәрҗемәләрнең библиографиясе зур түгел: ул үз эченә ике авторны һәм дүрт җыентыкны ала. Түбәндә аның тарафыннан тәрҗемә ителгән рус язучыларының исемнәре һәм әсәрләре китерелә:

1) А. С. Грибоедов: «Акыллылык бәласе» («Горе от ума») комедиясе [Грибоедов, 1945], [Грибоедов, 1946];

мәгънәсендә «эпик» эшчән итеп характерлаган ул вакытлар өчен һич тә җиңел булмаган юл сайлана. Эш шунда: Н. Исәнбәт дәверендә Советлар Берлегенең рус булмаган милләтләре (татарлар 1939 елдан кирилл алфавитын файдаланалар) дөнья әдәбиятының үрнәкләре белән чит әдәбияттан турыдан-туры түгел, ә «икенче кул» – рус теленә тәрҗемәләре аша танышырга тиеш дигән караш тарала һәм тиз арада гамәли шәкелдә тормышка ашырыла. Чит тел, гамәли аралашу белән аз бәйләнгән грамматика өйрәнүгә йөз тотып, схоластик формада укытыла, ягъни хәзер инглиз, алман, француз телләренең «совет диалекты» гамәлдә булган дип әйтергә билгеле бер нигез бар. Асылда, табигате белән китаби-язма, ә кулланылыш даирәсе буенча «өй», изоляцияләнгән дәүләт нәтиҗәсе булган «эчке» чит тел барлыкка китерелә. Әлбәттә, мондый чикләнгән формада телләр начар үзләштереләләр. Рус тәрҗемә мәктәбе, бәхәссез, лингвистик сәләтләре нәтиҗәсендә генә түгел, ә яшь вакытта чит илдә булу, башка дөньяны күрү һәм тану уникаль мөмкинлегенә ия булган шагыйрьләр һәм язучылар исеме (мәсәлән, С. Я. Маршак, К. И. Чуковский, яки М. Л. Лозинский) белән барлыкка китерелә. Н. Исәнбәт тә, күп татар совет тәрҗемәчеләре, Бөек Ватан сугышы елларында язмыш кушуы буенча Европада булган Ш. Мөдәррисне искә алмаганда, андый шартларга ия булмый (XX гасыр башында хәлле сәүдәгәр балалары, шагыйрьләр чит илләрдә булганда, аннан китаплар алып кайтып, аларны өйдә арадашчысыз тәрҗемә итә торган булалар). Моннан оригиналның мәгънәви ягын дөрес аңлау өчен тәрҗемәчеләрдән чиктән тыш зур көч таләп ителгәнлеге ачык күренә. М. Максуд француз теленнән «Кола Брюньон»ны тәрҗемә иткәндә, аерым урыннарны ачыклау өчен, М. Л. Лозинскийга мөрәҗәгать итә: алар икесе дә Язучылар берлеге әгъзасы була. «Гамлет» белән эшләгәндә, Н. Исәнбәт аннан ярдәм сорады микән, әлбәттә, без бу хакта төгәл әйтә алмыйбыз. Трагедиянең рус һәм татар вариантларын чагыштыру кайбер аерымлыклар булуын күрсәтә. Тәрҗемә хакында М. Л. Лозинский карашларын уртаклашкан хәлдә, Н. Исәнбәт туган татар теленең кагыйдәләре искә алынган үз юлы белән китә (кара: [Бекметов, Спирчагова, 2017]).

2) А.С. Пушкин: «Бакчасарай фонтаны» («Бахчисарайский фонтан»)» [Пушкин. Бакчасарай фонтаны, 1937, № 1], [Пушкин. Бакчасарай фонтаны, 1937] һәм «Полтава» поэмалары [Пушкин. Полтава, 1937], [Пушкин, 1950], «Таш кунак» («Каменный гость») фаҗигасе [Пушкин. Таш кунак, 1937], [Пушкин, 1949], [Пушкин, 1954].

Пушкинның ике – «Бакчасарай фонтаны», «Таш кунак» поэмаларының тәрҗемәләрен кыскача шәрехлик. А. С. Пушкин һәм А. С. Грибоедовның драма тәрҗемәләрендә геройларны һәм предметларны сурәтләүнең бөтенләй башка һәм үзенчәлекле сәхнә логикасы гамәлгә куелу сәбәпле, алар махсус өйрәнүне сорый. Ә аны театр сәнгатен гаҗәеп дәрәҗәдә оста бәяләгән Нәкый Исәнбәт бик яхшы белгән һәм бу алымнардан файдаланган; без аларны биредә анализламыйбыз.

А. С. Пушкинның атаклы поэмаларына күчик.

Аларның татар теленә тәрҗемә ителү фактында төп ике шарт– социаль заказ һәм эчке әдәби ситуация – хәлиткеч роль уйный.

Чыннан да, 1937 елда Советлар Берлегендә А. С. Пушкин үлеменең 100 еллыгы зурлап, киң колач белән билгеләп үтелә. Сталин миф тудыру дәверенең һәр тормыш күренешендәге идеологик элемент, төсмер белән бу вакыйга да характерлана. А. С. Пушкин, гәрчә шагыйрь мифы, аеруча рус сүз сәнгатенең «сикерешле», «тизләтелгән» үсешендә А. С. Пушкинның бары тик көнбатыш мәдәни җирлегендә генә гаять зур күренеш буларак барлыкка килү мөмкинлеген һәм аның әһәмиятен объектив шәрехләүне таләп итсә дә, классик йөзьеллык күгендә бердәнбер шагыйрь буларак танылa (ә пролетариат мәдәниятендә В. В. Маяковский шушы рольне уйный)[2].

Эстетик процессның күренекле, талантлы бер фигурасын аерып алып, аны халыкның өметләрен (идеалларын, ышанычларын. – *Р. Б.*) чагылдыручы сыйфатында тану гомумсовет тенденциясе, ул вакыт өчен табигый күренеш була. Бу кагыйдә рус әдәбиятына гына түгел, СССР халыкларының милли сүз сәнгатьләренә

[2] Бу – рус классикасының берьяклы идеяләр һәм стиль монологизмыннан азат булган күп векторлы, күп вариантлы табигатен күрсәтә. Оригинал лирикасы XX гасыр башында зур яңгыраш алып югары бәяләнгән һәм шул чорның мәкаләләрендә символизм хәбәрчесе, «Россия Гетесе» буларак характерланган Ф. И. Тютчев масштаблыгы белән А. С. Пушкин белән бер рәткә куела алмыймыни?

дә карый: украин әдәбиятында Тарас Шевченко пропагандаланган һәм иҗтимагый якланган гомуммәхәббәт культына ия була, казах сүз сәнгатендә – Абай (Ибраһим) Кунанбаев һәм Җамбыл Җабаев, татарда – Габдулла Тукай [Фридерих], [Гилазов, 2010], [Гилазов, 2013], (сугыштан соңгы елларда – Муса Җәлил), төрекмәндә – Мәхтүмкули: бу исемлекне тагын да дәвам итәргә булыр иде... Алар популяр һәм академик серияләрдә хәзерге вакыт үлчәмнәрендә акылга сыймаслык чиксез зур тиражларда нәшер ителәләр, дөнья телләренә тәрҗемә ителәләр (Н. Исәнбәтнең дә А. С. Пушкиннан тәрҗемәләре нәкъ менә 1937 елда басыла. – *Р. Б.*) алар хакында шәхси, аерым мәкаләләр һәи коллектив монографияләр языла – кыскасы көчле идеологик машина, материаль һәм финанс чыгымнары белән исәпләшмичә, «сакраль», изге мәгънәләр җитештерүче фабрика барлыкка китерә, ә монда тәрҗемәчеләр иң якыннан катнашалар. Моннан шулай ук Н. Исәнбәт тә чыгарма түгел[3].

Мәгълүм булганча, татар халкының иҗтимагый-рухи һәм мәдәни яңарышы чорында аерым газеталар-журналлар редакциясендә тәрҗемәчеләр клубы оештырыла, «тәрҗемәчеләрнең яңа буыны формалаша: С. Рахманколый, И. Богданов. В. Әхмәдуллин, Г. Кәрам, В. Апанаев, И.Казаков. Алар белән янәшә Г. Тукай, Ф. Әмирхан, Г. Камал, С. Рәмиев, Г. Исхакый, Г. Рәхимнәр бу эшкә актив катнашып китәләр» [Нагуманова, с. 73]. Тәрҗемә әсәрләренең саны көннән-көн арту, аңа ихтыяҗ үсү татар галимнәренең, тәнкыйтьчеләренең тәрҗемәнең теоретик нигезләре, төрләре, принциплары һәм ысуллары хакында уйланырга, барлыкка килгән тәҗрибәне өйрәнүгә һәм нәзари гомумиләштерүгә этәрә. Мәсәлән, Г. Тукайның бу тармакта аеруча осталыгы, тәрҗемә эшен әдәби иҗат дәрәҗәсенә күтәрүе югары бәяләнә [Галиуллин, Хабутдинова, с. 56–57].

XX гасыр беренче утызеллыгы татар мәдәнияте һәм әдәбиятының күренекле язучысы, әдәбият галиме Г. Ибраһимов «татар халкының психологиясенә вә тәрәккыяте фикриясенә мөнасиб булырлык (фикер үсешенә туры килерлек), аларның бер ярасына шифа бирерлек вә бер ихтыяҗларын капларлык булган бер әсәрне сайлау») [Ибраһимов, 6 т., 2019, б. 56] принцибын мөһим дип саный. Галимнәр, иҗат кешеләре С. Сүнчәләйнең А. С. Пушкиннан «Вәхи», Байроннан «Тоткын», Г. Гейнедан «Әлмансур»ны тәрҗемә итеп, Шәрык һәм Гаребнең күренекле язучыларының әдәби хәзинәләреннән бу көнгәчә мәхрүм булган татарларны таныштыруын югары бәяли [Ибраһимов, 7 т., 2019], [Казанлы]. Әмма шагыйрьнең күп әсәрләрне, аеруча «Әлмансур»ны миллиләштерәм дип, асылын үзгәртүе гафу ителмәслек «әдәби җинаять» төсендә тискәре мөнәсәбәт ала [Ибраһимов, 7 т., 2019, б. 67]. Күренә ки, 1910 еллар гыйльми-тәнкыйди фикере тарафыннан тәрҗемәчеләргә, әдәби эшчәнлекнең бу төренә югары таләпләр куелган. Шул рәвешле Аурупа-рус язучыларына мөнәсәбәт формалаша, алар әсәрләренең идея-эстетик кыйммәте кыйммәте билгеләнә.

Татар укымышлылары даирәсендә XIX ахыры – XX гасыр башында беренче танышудан башлап гений А.С. Пушкинга мөнәсәбәт аеруча зур җаваплылык, сак караш белән характерлана. Иң беренче нәүбәттә, А. С. Пушиннан тәрҗемәләре, аның әсәрләренең иректе күчерелүләре, икътибаслары белән

---

[3] Шуны ачыкларга кирәк: тәрҗемә ителгән язучылар, бәхәссез, мактауга лаеклы иделәр. А.С.Пушкин – «рус поэзиясенең кояшы» гыйбарәсе белән кем бәхәсләшер? Мәсьәлә менә нәрсә дә, халыкчан килеп чыгышы я булмаса гади халыкка теләктәшлеге сыйфаты буенча бер шәхесне алгы планга чыгарып, совет идеологиясе тарихы берничә гасырларга сузылган мәдәниятләрне артык гадиләштерә. Г. Тукай бөек, әмма татар әдәбияты аннан башка элитар, хәрәкәт векторының рухы белән аристократ, әмма «милли-буржуаз элементлар», ягъни «социаль яктан чит» катлавына кертелгән Дәрдемәндкә дә ия була. Муса Җәлил Советлар герое пантеонына кертелү сәбәпле, аның иҗаты үтә уңай бәя ала. Тирән анализга дәгъва итмичә, шагыйрьнең башлангыч чор әсәрләре белән танышу аларның сәнгати яктан үлем тырнагында рухи киеренкелек һәм ихтыяри тырышлык җимешләре «Моабит дәфтәрләре» белән чагыштырганда камил түгеллеген раслый. Совет властеның, Җамбул белән булган кебек, шагыйрьне көнүзәгендәге иҗтимагый мәсьәләләргә юнәлтелгән тематик линиядә ясалма үстерү омтылышы (бу дала акыны тарафыннан язылганнарның күбесе, авторлык хокукы буенча аңа карамый; текстларның күпчелеген әүвәл гадәти казах мөнәҗәтләре, шигъри әсәрләре стилендә урта кул рус шагыйрьләре яза, ә яңадан алар Җамбул тарафыннан аның якын даирәсендәге кешеләрнең кыска сөйләп бирүләре һәм ачыклаулары нигезндә туган телгә күчерелә, болар бөтенесе казах теленнән тәрҗемә итеп тәкъдим ителәләр [Джамбул Джабаев]), алар конкрет сыйфат, үзенчәлекләр хакында сораулар тудырмыйча калдырмый.

тәкъдир ителгән үзенчәлекле татар пушкинианасы яши; яңа ысул мәктәпләренә кертелә башлаган җәдитчелек күрсәтмәләренә (рус теле югары белем бирү теле итеп таныла, шуның аркасында фәнгә, сәнгать өлкәсенә һәм дәүләт тормышына ишек ачыла. – *Р. Б.*) мантыйкый нигезләнгән җавап төсендә рус классикасының иң югары дәрәҗәсе дип танылган культ урнаша.

Әлбәттә, тәрҗемәгә бөтен әсәрләр дә түгел, ә сурәтләнгән мәдәни-географик һәм дини реалийлары якын булган иҗат җимешләре генә алына.

Шулай М. Ю. Лермонтовның, роман бөтенлеген җимереп һәм «Безнең заман герое» («Герой нашего времени») составындагы повестьларга игътибар итмичә, «Ашик-Кериб» (Ашик – Гариб / Ашуг – Гариб) төрек экиятен, яисә «Бэла»сын тәрҗемә итү артыграк күрелә: рус язучысы тарафыннан теләктәшлек белән сурәтләнеп, хатын-кызлар язмышы хакында сентименталь уйланулар белән бер яссылыкта булган яшь тәҗрибәсез кыз язмышы кызыксыну уятмыйча кала алмый (Н. М. Карамзин «Бичара кызы»ның («Бедная Лиза»), персонажлар исемен, сюжет барышын һәм шартларны, туган, күнегелгән реальлеккә җайлаштыру нияте белән татарчалаштырып, ирекле рәвештә үзгәртеп тәрҗемә ителүе игътибарга лаек. – *Р.Б.*); Л. Н. Толстойдан – теләсә нинди властька әхлакый тәэсирлелеккә буялган горур каршылыгы белән «Хаҗи Мурат»ы («Хаджи Мурат») кавказ повесте татарчалаштырыла. Аларны күп тапкырлар тәрҗемә итәләр, ә бәясе зур булмаган китап-рисаләләр тиз арада сатылып бетә. Н. Исәнбәт, әлбәттә, бөтен татарлар яраткан А. С. Пушкинны тәрҗемә иткәндә, элгәргеләр тәҗрибәсен искә алган.

Ул «Полтава»ны, күрәсең, мөхәррир сайлавы белән заказ буенча тәрҗемә иткән: беренчедән, 1930 еларда урнашкан идеологик монизм рус тарихының монументаль шәрехләнүенә ярдәм итә, аны СССРның рус булмаган халыкларына тапшырырга кирәк була; икенчедән, Язучылар берлегенең милли бүлекләре планына бөек шагыйрьне киң масштабта таныту бурычы кертелә, ә ул, үз чиратында, А. С. Пушкинның татарчага тәрҗемә ителмәгән әсәрләрен нәшер итүне көн тәртибенә куя. «Бакчасарай фонтаны»на («Бахчисарайский фонтан») килгәндә, Н. Исәнбәткә кадәр бу көньяк поэмасын тәрҗемә итәләр, башкача була да алмый – биредә Идел буе татарларының тарихи тамырлары белән, Алтын Урда таркалып, Казан ханлыгы оеша башлау чорына һәм Гәрәй династиясе вәкилләренең Казан тәхетендә (кырым партиясе. – *Р. Б.*) идарә итүләренең иң югары ноктасы вакытына барып тоташкан Кырым сурәтләү объекты булып тора.

1899–1900 елларда А. С. Пушкин поэмасын Мөхәммәд-Сәлим Өметбаев тәрҗемә итә, һәм, әлбәттә, ул тикшерелеп, Санкт-Петербуг цензурасының 1900 елның 27 ноябре белән даталанган махсус рөхсәте бирелгәннән соң, Казанда Б. Л. Домбровскийнең шәхси матбагасында дөнья күрә [Пушкин, 1901][4].

Хәзер «Бакчасарай фонтан»ының ике тәрҗемәсеннән сайлап алынган өзекләрне чагыштырып карау максатка ярашлы булыр. Пушкин поэмасының куәтле дәүләтнең башлыгы Гәрәй тасвирланган өзеген – башламын алыйк.

| А.С. Пушкин. «Бахчасарай фонтаны» | Сәлим Өметбаев тәрҗемәсе («Бахчасарай фонтаны», 1900) | Нәкый Исәнбәт тәрҗемәсе («Бакчасарай фонтаны», 1937) |
|---|---|---|
| 1. Гирей сидел, потупя взор;<br>2. Янтарь в устах его дымился;<br>3. Безмолвно раболепный двор<br>4. Вкруг хана грозного теснился.<br>5. Все было тихо во дворце;<br>6. Благоговея, все читали<br>7. Приметы | 1. Утырып (утыра) Бахчасарайда, / Түбән карап Гәрәй хан.<br>2. Авыздагы янтарьдан / Уйнатадыр иде дәхан (төтен);<br>3. Яранлары (иптәшләре, дуслары) тып-тыныч / Чура янларын ләмыш (түгәрәкләп урын алганнар), | 1. Гәрәй утыра иде карап түбән,<br>2. Хур-хур төти иде авызында;<br>3. Якыннары колдай башын игән,<br>4. Сыенып дәһшәтле хан алдында.<br>5. Бар да тып-тын иде бу сарайда;<br>6. Зурлап аны ихлас күңелдән,<br>7. Ачу, кайгы |

[4] Өметбаев Мөхәммәд-Сәлим Ишмөхәммәт улы (1881–1907) күренекле башкорт мәгърифәтчесе, шагыйрь, тәрҗемәче, филолог, этнограф, җәмәгать эшлеклесе, Рус географик җәмгыятенең Оренбург бүлеге һәм А. С. Пушкин тууының 100 еллык юбилеен бәйрәм итү комиссиясенең әгъзасы, моннан тыш вакыф эшләре (Исламда. – милеккә бәйләнгән. – *Р. Б.*) Россия Эчке эшләр министрлыгының Кырым комиссиясе составына кергән. Аның турында һәм фәнни-әдәби иҗаты хакында кара: [Өмөтбаев, б. 5–62]. Басма поэманың тышында тәрҗемәченең фамилиясе һәм исеме алдыннан, маркировкалаучы рәтнең бәрәмлеге буларак «башкорт» сүзе куелган (чагыштыр: «мөтәрҗемә: башкорт Мөхәммәдсәлим Өмөтбаев»).

| | | |
|---|---|---|
| гнева и печали<br>8. На сумрачном его лице.<br>9. Но повелитель горделивый<br>10. Махнул рукой нетерпеливой:<br>11. И все, склонившись, идут вон [Пушкин, 1986: с. 48]. | 4. Гәрчә сарай фәрагать (тынлык, ял), / Ханның йөзе саргаймыш.<br>5. Кылды Гәрәй мәһабәт / Кулы илә (белән) ишарәт,<br>6. Халкы тышка(ры) (ук) чыгып, / Кылды (буйсынып хөрмәт).<br>7. Ялгыз калып сарайда, / Шәп тын ала күкрәге,<br>8. Газаплы баш тулкының, / Басыр им(н)де йөрәге.<br>9. Болыт та шулай беленер, / Яннарында күренер,<br>10. Пыялага кыелса, / Гаксе беленер рәңле (төрле төстәге) нур,<br>11. Горурлыкмы ханыңа? / Төште сәүда (уй-теләк) жанына [Пушкин, 1901: 2], кара.: [Өмөтбаев. 2011: б. 170]. | эзен алар бар да<br>8. Укый аның сүнгән йөзеннән.<br>9. Ләкин мәгърур хаким түзмәде,<br>10. Кулын гына селтәп җибәрде,<br>11. Бар да иелеп тышка тотты юл [Пушкин, 1950: б. 63]. |

С. Өметбаевның төрки телгә тәрҗемәсе классик төрки-татар (киңрәк – шәркый. – *Р.Б.*) поэтиканың шигырь төзелешенә яраклаштырылган. Мисраглар яртыюллыкларга бүленгән, ритмикада җиңеллекне тәэмин итү өчен, мисрагларда, шул исәптән яртыюллыклар эчендә дә парлы рифма еш кулланыла. Текст стиле күренешне аңлатуга йөз тота (оригинал чикләре бозылганда: мәсәлән, оригиналның 11 юлы – тәрҗемәдә бу 6 юл. – *Р.Б.*). А. С. Пушкин әсәрендә романтик сер бар: шагыйрь сарайда Гәрәй дулкынлануы хасил иткән тынлык сурәтен тудыра. Әлеге өзектә бу халәтнең сәбәбе турында әйтелми: автор хикәяләүне сер пәрдәсенә, томанына төрә; өченче строфада ул риторик сораулар кую аша «*горур падишаһ*» – хан «*караңгылыг*»ының сәбәпләре хакында укучыны уйланырга (аның белән бер үк хокукларда үзе дә уйлана. - *Р.Б.*) мәҗбүр итә: («*Горур җанны нәрсә хәрәкәт иттерә? Нинди уй белән ул мәшгуль*») [(«*Что движет гордою душою? / Какою мыслью занят он?..*»)] (сүзгә-сүз тәрҗ. – *Р. Б.*). Татар тәрҗемәчесе үзгәрешләр кертеп, автор артыннан бара: әйтик, хан образында хакимлек итәргә яратучанлыкны көчәйтү өчен, аның кулын, гәрчә уч зурлыгы оригиналда Гәрәйнең ризасызлыгын чагылдырса да, «*мәһабәт кул*» дип сыйфатлый. С. Өметбаев тәрҗемәсендә Сәгъдинең «Бустан»ыннан алынган эпиграфның юклыгын билгеләргә кирәк. Бу факт теләсә нинди сюжеттан тыш элементның әсәр идеясе һәм уйланмасының бер өлеше булганга гына түгел, ә Сәгъдинең лириклыгы турында тәрҗемәченең хәбәрдар булуы ягыннан гаҗәп; моннан тыш ул поэманы фарсы әдәбияты темасының яңгырашы буларак та кабул итәргә мөмкин иде; Сәгъдидән өзекне кертү татар укучылары алдында А. С. Пушкинның дәрәҗәсен күтәрер, аларга якынайтыр иде.

Н. Исәнбәттә алай түгел. Ул, сурәтне бирүдә иреклелеккә ирешмәсә дә, аны шик астына алган мәдәни-тарихи контекстта тора. Принцип бер – үзеңнең киң карашлы иҗат шәхесе булуыңны арткы планга калдырып, тасвирны саклык белән аңлату. Беренче урында – А. С. Пушкин, аның образлы фикерләре. Парлы рифманың юклыгы һәм аның тулы булмаса да авторныкына туры килүе (оригиналда – АБАБВГГВДДЖ, тәрҗемәдә – АБАБВГВГДДЖ) шуның белән аңлатыла. Тәрҗемәнең һәр юлы мәгънәсе белән төп нөсхә мисрагларына аваздаш. Бередә сүзләр кулллanылышы да төгәл: «*к о л д а й башын игән*» – «*раболепный*», «*Ачу, кайгы эзен алар бар да / У к ы й...*» – «*... все читали / Приметы гнева и печали*» (хан йөзендәге билгеләр китапның мәгънәсе аңлашылганча укыла), «*Кулын гына с е л т ә п җ и б ә р д е*» – «*Махнул рукой*», «*Бар да... т ы ш ка т о т т ы ю л*» – «*... идут вон*» (ассызык. – *Р.Б.*). Мондый төгәллек ирекле укуны яисә дөрес булмаган шәрехләүләрне – нюансларда! – кире какмый. Киресенчә, алар билгеле бер күләмдә, я булмаса элементар очраклылык тәртибендә (ул күренекле сәнгать осталарында да була. – *Р.Б.*) күз алдында тотыла. Төп нөсхәдә «(хан) *йөзе*» (лицо (хана)) – «*караңгы*» (сумрачное). Тәрҗемәдә сизелерлек йомшарту күзәтелә: Исәнбәттә «йөз» Пушкинда булмаган көчсезлек, арыганлык, физик һәм рухи төшенкелек билгесе булган «сүнгән» сызыгын

(«*сүнгән йөзе*», чагыштыр: «*сүнгән йолдыз*») ала. Туры килгән, башка эпитетны сайлау дөрес булмас иде: «караңгыланган» (хан күңелсез уйларга баткан, тирә-яктагы дөнья инде аны кызыксындырмый, һәм бүгеннән йөзе «төннән дә карарак», «караңгылыктан да карарак», «болыттан да карарак»)? Шул ук вакытта Н. Исәнбәттәге лексемалар сайланышын тупас хата дип санарга ярамый: «ярым караңгылык» (эңгер-меңгер) – көн кичкә авышкан, караңгылык иңгән, кояш горизонт артында батып сүнгән вакыт, һәм төн башлана. Н. Исәнбәт А. С. Пушкин эпитетын артык туры кабул иткән: аның караңгылыгы күңелдәге караңгылык түгел, ә яктылык бетү, юкка чыгу. Монда, әлбәттә, оригинал белән тәңгәл килү / тәңгәл килмәү критерийларының төсмерләре мөһим. Бу тәрҗемәчене автор сүзен бозуда гаепләү өчен ассызыкланган очрак та түгел. Гомумән алганда, текст төптән, тирәнтен уйланып тәрҗемә ителгән, аны татарча укысалар да, Пушкин үзенә тугры калган.

«Полтава»ның барлык күренешләреннән поэманың кульминацион ноктасы – руслар белән шведлар арасындагы сугыш эпизодларына тукталу һәм Н. Исәнбәт тәрҗемәсендә төп нөсхәнең мәгънәләре үзгәрешен карау урынлы булыр.

| А.С. Пушкин. «Полтава» | Нәкый Исәнбәт тәрҗемәсе (1937) |
|---|---|
| 1. И грянул бой, Полтавский бой! | 1. Полтава сугышы күкрәде! |
| 2. В огне, под градом раскаленным, | 2. Утлы яңгыр, ялкын эчендә, |
| 3. Стеной живою отраженным, | 3. Җанлы койма бәргәч кирегә, |
| 4. Над падшим строем свежий строй | 4. Авып калган сафлар өстенә |
| 5. Штыки смыкает. Тяжкой тучей | 5. Яңа сафлар килеп менде дә |
| 6. Отряды конницы летучей, | 6. Штык сузды берсе-берсенә. |
| 7. Браздами, саблями звуча, | 7. Атлы гаскәр чапты агылып, |
| 8. Сшибаясь рубятся с плеча. | 8. Авыр болыт кебек узып бары, |
| 9. Бросая груды тел на груду, | 9. Тезгеннәре, шыңрап кылычлары, |
| 10. Шары чугунные повсюду | 10. Кисешәләр бәрелеп, абынып. |
| 11. Меж ними прыгают, разят, | 11. Тәннәр өеп тәннәр өстенә, |
| 12. Прах роют и в крови шипят. | 12. Чуен шарлар һәммә урында, |
| 13. Швед, русский – колет, рубит, режет, | 13. Ыргый, кисә, алар эчендә |
| 14. Бой барабанный, клики, скрежет. | 14. Туфрак казып, канда сызгыра. |
| 15. Гром пушек, топот, ржанье, стон, | 15. Суеша швед һәм рус, кисеш, кырылыш, |
| 16. И смерть, и ад со всех сторон [Пушкин, 1986: с. 120]. | 16. Барабаннар, чыр-чу, ул кычкырыш. |
| | 17. Кешнәү, иңрәү, яңрый тояк, туп, |
| | 18. Һәммә яклап үлем һәм тәмуг [Пушкин, 1950: б. 52–53]. |

А. С. Пушкин өчен сугыш – ул стихияләр хаосы, кайгы-хәсрәтләрнең һәм чиксез газапларның туктаусыз хәрәкәте. Зур сугышларда ут беренчел элементының тантанасы тормышка ашырыла. Без, тирә-якны кырып һәм тирән чокырлар чокып, «*канда чыжылдау*» өчен «*чуен шарларының*» тәнгә тиюн күрәбез. Кагыйдә буенча, тимерче алачыгында кызыл төскә кергәнче кыздырылган металл оста тимерче тарафыннан, суыту нияте белән, салкын суга батырылгач «*чыжлый*». Әмма бу конкрет очракта кайнар чуен рус тигезлекләрендә су белән алыштырылган кан белән натуралистларча суына. Шагыйрь сугыш-үтерешне тасвирлап, эстетик игътибарны тизләтелгән темпта предметтан хәрәкәткә күчерә, ул сөйләмдә исемнәрне фигыльләр белән аралаштыра. Пушкин сугышы – тәннәр катнашмасының, вакыйгалар өермәсенең, хисләр ярсуының, көчләр ташкының пластикасы. Шагыйрь сугышның югары-куркыныч яңгырашын, көен тотып ала, ул аны куркыта да, сокландыра да.

Н. Исәнбәт, бу нечкә, гадәттән тыш нотаны, яңгырашны ишетү сәбәпле, төп игътибарын лексик берәмлекләр сайлауга түгел, ә мисрагларны фонетик формалаштыруга юнәлтә. Каршылыклар көчәя барган сугыш күренешләре белән саңгырау тартыклар кабатлануының артуы идарә итә: (*йомык һәм ярым-йомык [к], [h]) «кисешләр», «канда», «казып», «кешнәү», «һәммә», «һәм»; калтыраулы ([р]): «авыр», «тәннәр», «ыргый», «барабаннар», «яңрый»; чыжылдаулы ([ш], [ч]): «шарлар», «кисеш», «кырылыш», «кычкырыш», «шыңрап», «чыр-чу»* белән тәэмин итеPлә. Шигырь юлларының туры килмәве (тәрҗемә ике мисрагка артыграк. – *Р.Б.*), татар теле өчен мөһим булып, табигый яңгыраган ритмик-интонацион момент, поэтик һәм, метрик үлчәм белән интонацион-синтаксик бәйләнешләр тәңгәл килмәү

аркасында, фразаларның бер өлешен икенче юлга күчерүләр (анжамбеманнар. – *Р. Б.*) («*Авып калган сафлар өстенә / Яңа сафлар килеп менде дә / Штык сузды берсе-берсенә*»), сурәтне тагын да тәэсирлерәк, матуррак итә торган лексик-мәгънәви кабатлаулар белән («…*сафлар өстенә / Яңа сафлар...», «Тәннәр өеп тәннәр өстенә*») компенсацияләнә.

Күзәтүләргә нәтиҗә ясап, шуны әйтергә мөмкин: Н. Исәнбәт үзенчәлекле тәрҗемә формасын эшли. А) төп нөсхәнең мәгънәсен бирү, б) яңа күчермәнең туган тел кагыйдәләренә туры килүе, в) әсәрдә чагылган территориаль-географик һәм тарихи-социаль пландагы чит реалийларны тирән һәм җентекле белү аның стиленең состав элементлары булып тора.

Гомумән алганда, әгәр дә әдәби тәрҗемәнең совет мәктәбен күздә тотсак, бу караш яңа түгел. Н. Исәнбәт тәрҗемәчелек стратегиясенә аның карашларын билгели торган «үз вакытында» яши. Әмма аның ысулы, юлы татар туфрагында кыйммәтле нәтиҗәләр бирә һәм алар яңа тәрҗемәчеләрнең, тәҗрибәләр ясауның ялгыш аңланган караңгылыгында адашмыйча, Н. Исәнбәтнең (аның белән башка тәрҗемәчеләр, күренекле замандашлары да була – *Р.Б.*) авыр, тырыш хезмәте белән барлыкка китерелгән осталыкның югары нормасын ачык күзалласыннар өчен, бүген филологик аспектта аңланылырга тиеш.

«Тәрҗемәче буларак Нәкый Исәнбәт» темасы киләчәктә махсус-системалы өйрәнүләрне көтә. Бу юнәлештә нәзари эзләнүләр актив дәвам итәр дип ышанасы килә.

**Әдәбият**

Әдипләребез: биобиблиографик белешмәлек: 2 томда. Т. I: А – К / төз. Р. Даутов һәм Р. Рахмани. Казан: Татарстан китап нәшрияты, 2009. 751 б.

*Грибоедов А. С.* Акыллылык бәласе / кыскартып тәрҗемә итүче Нәкый Исәнбәт // Совет әдәбияты. 1945. № 1. Б. 14–22.

*Грибоедов А. С.* Акыллылык бәласе / Нәкый Исәнбәт тәрҗемәсе. Казан: Татгосиздат, 1946. 118 б.

*Ибраһимов Г. Г.* Тәрҗемә һәм аның шартлары // Әсәрләр: 15 томда: 6 т.: Әдәбият һәм сәнгать турында мәкаләләр, хезмәтләр (1910–1914) [төз., текст., иск. һәм аңл. әзерл. З. Г. Мөхәммәтшин; кереш сүз авт. Д. Ф. Заһидуллина]. Академик басма. Казан: Татарстан китап нәшрияты, 2019. Б. 55–57.

*Ибраһимов Г. Г.* Яңа әсәрләр, яңа имзалар вә яшь куәтләр // Әсәрләр: 15 томда: 7 т.: Әдәбият һәм сәнгать турында мәкаләләр, хезмәтләр (1915–1916) [төз. Г. М. Ханнанова, З. Г. Мөхәммәтшин; текст., иск. һәм аңл. әзерл. З. Г. Мөхәммәтшин; кушымта һәм исем. күрсәт. әзерл. Г. М. Ханнанова; кереш сүз авт. Д. Ф. Заһидуллина]. Академик басма. Казан: Татарстан китап нәшрияты, 2019. Б. 61–70.

*Казанлы Ф-С.* Тәрҗемә бабында тәҗрибәләр («Әл-Мансур» мөнәсәбәте белән) // Аң. 1914. № 4. Б. 83–85; № 5. Б. 103–104; № 8. Б. 165–168; № 9. Б. 180–182 .

*Нагуманова Э. Ф.* Современная татарская поэзия в переводе на татарский язык. Tatarica. 2017. № 1 (8). С. 63–82.

*Өмөтбаев М.-С.* Йәдкәр: шиғырҙар, публицистик, тарихи этнографик яҙмалар, тәрҗемәләр, халыҡ иҗады өлгөләре. Өфө: Китап, 2011. 344 б.

*Пушкин А. С.* Бакчасарай фонтаны / Нәкый Исәнбәт тәрҗемәсе // Совет әдәбияты. 1937. № 1. Б. 27–41.

*Пушкин А. С.* Бакчасарай фонтаны / Нәкый Исәнбәт тәрҗемәсе. Казан: Татгосиздат, 1937. 40 б.

*Пушкин А. С.* Бахчасарай фонтаны / мөтәрҗемә: М.-С. Өмөтбаев. Казань: Типография Б. Л. Домбровского, 1901. 16 б.

*Пушкин А. С.* Полтава / Нәкый Исәнбәт тәрҗемәсе. Казан: Татгосиздат, 1937. 71 б.

*Пушкин А. С.* Полтава. Бакчасарай фонтаны / Нәкый Исәнбәт тәрҗемәсе. Казан: Татгосиздат, 1950. 82 б.

*Пушкин А. С.* Таш кунак / Нәкый Исәнбәт тәрҗемәсе // А. С. Пушкин Сайланма әсәрләр. Казан: Татгосиздат, 1949. Б. 634–667.

*Пушкин А. С.* Таш кунак / Нәкый Исәнбәт тәрҗемәсе // А. С. Пушкин Сайланма әсәрләр 2 томда. Казан: Татгосиздат, 1954. Б. 672–703.

*Пушкин А. С.* Таш кунак / Нәкый Исәнбәт тәрҗемәсе. Казан: Татгосиздат, 1937. 51 б.

*Аврутина А. С., Хабутдинова М. М.* Назым Хикмет и татарская культура // Tatarica. 2018. № 2. С. 61–77.

*Бекметов Р. Ф., Спирчагова Т. А.* Трагедия Шекспира «Гамлет» в русском и татарском переводах: М. Лозинский и Н. Исанбет // Филология и культура. Philology and culture. 2017. № 2 (48). С. 133–138.

*Галиуллин Т. Н., Хабутдинова М. М.* Западноевропейская классика в переложениях Г. Тукая // Tatarica. 2014. № 1(2). С. 49–61.

*Гилазов Т.Ш.* Трансформация взглядов на творчество Г. Тукая в 1920–1930-х годах // Вестник Челябинского государственного университета. Филология. Искусствоведение. Выпуск 43. 2010. № 13. С. 19–25.

*Гилазов Т.Ш.* Проблема литературной репутации Г. Тукая в научно-критической мысли первой четверти XX века. // Филология и культура. Philology and culture. 2013. № 3(33). С. 181–185.

*Джамбул Джабаев*: приключение казахского акына в советской стране. М.: Новое литературное обозрение, 2013. 308 с.

*Пушкин А. С.* Сочинения: в 3 томах. Т. II: Поэмы. Евгений Онегин. Драматические произведения. М.: Художественная литература, 1986. 527 с.

*Сайфулина Ф. С., Валеева А. З.* Фатих Кутлу как переводчик и пропагандист татарской литературы в Турции. Tatarica. 2017. № 2(9). С. 42–64.

*Фредерик М.* Габдулла Тукай как объект идеологической борьбы / пер. с нем. И. А. Гилязова. Казань: Татарское книжное издательство, 2011. 343 с.

# НАКИ ИСАНБЕТ – ПЕРЕВОДЧИК РУССКОЙ КЛАССИЧЕСКОЙ ЛИТЕРАТУРЫ

**Ринат Ферганович Бекметов,**
Казанский федеральный университет,
Россия, 420008, г. Казань, ул. Кремлевская, д. 18,
bekmetov@list.ru.

В статье рассматривается переводческая деятельность Наки Исанбета. В качестве материала для анализа были взяты его переводы произведений русской классической литературы, в частности отдельные фрагменты из переводов «Бахчисарайского фонтана» и «Полтавы» А. С. Пушкина. Были затронуты вопросы культурно-идеологического контекста обращения к русской классике, технического новаторства в сравнении с предшественниками, а также проблемы, связанные с принципами переводческой работы мастера. Важными составными элементами стиля Наки Исанбета как переводчика являются точность передачи смыслов оригинала, соответствие нового, переводного текста нормам родного (татарского) языка, его эстетическим приемам, глубина проникновения в воображаемый мир русской словесности. Тема, безусловно, требует дальнейшего исследования.

**Ключевые слова:** Наки Исанбет, русская литература, татарский язык, художественный перевод, сравнение и сопоставление, смысловые трансформации.